РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.11.2022 № 1151-п

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасын раслау турында» (алга таба - Программа) 2020 елның 21 октябрендәге 1408-п номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Программа паспорты таблицасында:

- «Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 2021 - 2025 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 2 152,900 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 елда - 415,550 мең сум;<br>2022 елда - 537,350 мең сум;<br>2023 елда - 400,000 мең сум;<br>2024 елда - 400,000 мең сум;<br>2025 елда - 400,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |

»;

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итү» 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**3. Программаны ресурслар белән тәэмин итү**

Программаны финанслауның гомуми күләме 2021 - 2025 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 2 152,900 мең сум тәшкил итә, шул

исәптән:

2021 елда - 415,550 мең сум;
2022 елда - 537,350 мең сум;
2023 елда - 400,000 мең сум;
2024 елда - 400,000 мең сум;
2025 елда - 400,000 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

1.3. Программага 1 кушымтаны әлеге карарга 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы И.Р. Гариповка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 кушымта

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасына 1 кушымта

**«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасының төп чаралары**

| № т/б | Чаралар исеме | Уздыру вакыты | Җаваплы башкаручылар | Еллар буенча программаны финанслау күләмнәре, мең сум. | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
| **1.Оештыру чаралары** | | | | | | | | |
| 1.1. | Район гомуми белем бирү мәктәпләренең укыту-методик һәм матди-техник базасын ныгыту | даими рәвештә | Мәгариф идарәсе | | | | | |
| **2.Яшь гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү** | | | | | | | | |
| 2.1. | Балаларга һәм яшьләргә әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү буенча семинарлар оештыру һәм уздыру | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 2.2. | Геройлар, Бөек Ватан сугышы, тыл хезмәтчәннәре турында китаплар буенча уку конференцияләре үткәрү. Рефереатларны һәм иҗади эзләү-тикшеренү эшләрен әзерләү | ел саен | Мәгариф идарәсе | | | | | |
| 2.3. | «Россия паспорты көне» паспортлар тапшыру буенча яшьләр-патриотик акциясе үткәрү | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, РФ Федераль миграция хезмәтенең ТР буенча Саба районындагы бүлеге | | | | | |
| 2.4. | Җәмәгать тәртибен саклау формированиеләренең матди базасын ныгыту | ел саен | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Саба районы | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | буенча бүлеге, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 2.5. | “Гражданлык һәм ватанпәрвәрлек сәгате” республика акциясен үткәрү | кварталга 1 тапкыр | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 2.6. | Танылган якташлар, район һәм республиканың тарихы һәм туган якны өйрәнү буенча экспозицияләр циклын оештыру «Ватаныбызны өйрәнеп, үзебез турында белербез» | ел саен | Башкарма комитетның мәдәният бүлеге, район туган якны өйрәнү музее, Мәгариф идарәсе | | | | | |
| 2.7. | Тарихи-туган якны өйрәнү музейларында, мәгариф музейларында экскурсияләр үткәрү һәм аларда катнашу | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 2.8. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча мәктәп формированиеләренең республика слётында катнашу | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге | | | | | |
| 2.9. | Балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау буенча отрядларны үстерү эше | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге | | | | | |
| 2.10. | Кадет сыйныфының уңышлы эшендә ярдәм итү | ел саен | Мәгариф идарәсе | | | | | |
| **3.Патриотик тәрбия бирү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чаралары, балалар һәм яшьләр арасында спорт чаралары** | | | | | | | | |
| 3.1. | Көз һәм яз көннәрендә чакырылырга тиешле хезмәткә чакырылучыларның Республика спартакиадасында катнашуы. | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 3.2. | Биш көнлек хәрби-кыр җыеннары үткәрү | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 287,690 | 313,963 | 180,000 | 180,000 | 180,000 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.3. | Саба муниципаль районы хәрби хезмәткә чакырылучылар арасында хәрби-гамәли спорт төрләре буенча район, зона ярышларында катнашу һәм үткәрү | Апрель, Октябрь ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.4. | Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга багышланган чаралар үткәрү | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.5. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең спартакиадасын үткәрү | Апрель, Октябрь ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге | | | | | |
| 3.6. | Хәрби хезмәткә чакырылучыларның физик әзерлеге буенча белем бирү учреждениеләренең смотр-конкурсларын үткәрү | Февраль-Март ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.7. | Армиягә алынучылар көнен үткәрү | Апрель, Октябрь ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Татарстан | 99,860 | 71,460 | 100,000 | 100,000 | 100,000 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.8. | Район спорт ярышларын үткәрү:<br>- волейбол буенча<br>- милли көрәш буенча;<br>- якташларыбыз-танылган спортчылар призына<br>- якташларыбыз-сугышчы-интернационалистлар истәлегенә багышланган<br>- Советлар Союзы Геройлары - якташларыбыз истәлегенә багышланган<br>һ.б. | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.9. | Техник спорт төрләрен (хәрби-гамәли төрләрен) үстерү | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.10. | Җиңү көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрү | Май,<br>ел саен | Программада катнашучыларның барысы да | 10,000 | 10,000 | 10,000 | 10,000 | 10,000 |
| 3.11. | Район уку йортларында хәрби дан көненә (җиңү көннәренә) багышланган батырлык дәресләре үткәрү, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, локаль сугышчыларның, тыл ветераннарының очрашуларын оештыру. | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.12. | Хәрби дан һәйкәлләре һәм мемориаллары патронажы | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.13. | «Аҗаган» хәрби-патриотик уены үткәрү | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | 7,000 | 43,700 | 7,000 | 7,000 | 7,000 |
| 3.14. | Якташларының хәрби һәм хезмәт батырлыклары турында материаллар өйрәнү һәм җыю эшен оештыру | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 3.15. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча район һәм республика конкурслары үткәрү һәм анда яшьләр (мәктәп) формированиеләре отрядларының катнашуы | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе | 11,000 | 98,227 | 103,000 | 103,000 | 103,000 |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | **415,550** | **537,350** | **400,000** | **400,000** | **400,000** |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | **2 152,900** | | | | |

Кулланган кыскартулар:

Мәгариф идарәсе - «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе;

ОДМС - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге;

район туган якны өйрәнү музее - "Саба үзәкләштерелгән туган якны өйрәнү музее" муниципаль бюджет учреждениесе (район туган якны өйрәнү музее);

Саба районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы - Саба районы буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге;

Саба муниципаль районындагы Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль пункты - Саба муниципаль районындагы Россия Миграция хезмәте идарәсенең территориаль пункты.